**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«15» 02 2023 ел Яр Чаллы № 526

Муниципаль район авыл җирлекләренең җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары, авыл җирлекләре чикләреннән читтә урнашкан 7 бакчачылык ширкәтенә керү юллары, «Түбән Кама» милли паркы территориясендә урнашкан сервитут юллары исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 декабрендәге 257-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнарны гамәлгә ашыру максатында,

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Муниципаль район авыл җирлекләренең җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары исемлеген» (1 кушымта), «Авыл җирлекләре чикләреннән читтә урнашкан 7 бакчачылык ширкәтенә керү юллары исемлеген» (2 кушымта), «Түбән Кама» милли паркы территориясендә урнашкан автомобиль сервитут юллары исемлеген» (3 кушымта) расларга.
2. «Муниципаль район авыл җирлекләренең җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары исемлеген раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2022 елның 15 февралендәге 399 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Ә.Р. Гәрәевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин